**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«07» ноябрь, 2025 ел Иштирәк авылы № 4

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлеге Уставы, Иштирәк авыл җирлеге Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының 08.11.2019 ел «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «Нигезләмәне раслау хакында»52/1 номерлы" карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Иштирәк авылының Үзәк урамы буенча 50А йорты янгын сүндерү депосы бинасы янында Иштирәк, Узәк урамнарында (авылның бер өлеше - авыл) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын 2025 елның 21 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә
2. Иштирәк авылы, Үзәк һәм С.Закиров урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын 2025 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3.Гражданнар җыенын үткәрү өчен Иштирәк авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билге буенча башкарырга кирәк.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда яшәү урыны буенча Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, аларның гаилэ әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үзәк урамындагы юлны ремонтлау)
- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычлары, эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру);

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы А.П. Васильева